ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.09.2022 Балык Бистәсе штп. № 253пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 18.10.2019 №293пи карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза үткәрү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле һәм муниципаль контроль турында" Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында " 11.06.2021 ел, №170-ФЗ Федераль закон нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 18.10.2019 №293пи карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү турындагы нигезләмәгә ( алга таба- Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең 1.1 пунктындагы 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге нигезләмә эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен артык вазыйфалар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының һәм җирле бюджетларның нигезсез чыгымнарына китерүче нигезләмәләрне ачыклау максатларында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру тәртибен билгели.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инвестицияләр җәлеп итү һәм мәгълүмати технологияләр мәсьәләләре буенча урынбасары А.А. Хәкимуллинга йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Р.Р. Ислямов